# Алгебраик аңлатмалар

**1.** Кайсы аңлатманың кыйммәте иррациональ сан була?

1) $\sqrt{20}\cdot\sqrt{5}$

2) $(\sqrt{24}-\sqrt{2})\cdot(\sqrt{24}+\sqrt{2})$

3) $\dfrac{\sqrt{32}}{\sqrt{18}}$

4) $\sqrt{18}-2\sqrt{2}$

**2.** $x=-\dfrac{1}{20}$ булганда, $(x-5)^2-x(10+x)$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**3.** Аңлатманы гадиләштерегез: $\dfrac{x+9}{x-3}-\dfrac{6}{x^2-9}:\dfrac{6}{(x+3)^2}-\dfrac{3x-3}{x-3}$.

**4.** $\dfrac{(x^3)^{-4}}{x^{-3}}$ вакланмасын түбәндәге кайсы аңлатмага үзгәртеп була?

1) $x^{-9}$

2) $x^{-15}$

3) $x^4$

4) $x^2$

**5.** x=18; y=7,5 булганда, $\dfrac{xy+y^2}{15x}\cdot\dfrac{3x}{x+y}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**6.** Түбәндәге очракларның кайсында $2\sqrt{3}$, $3\sqrt{2}$ һәм 4 саннары үсү тәртибендә урнашкан?

1) $3\sqrt{2}$; 4; $2\sqrt{3}$

2) $2\sqrt{3}$; 4; $3\sqrt{2}$

3) $2\sqrt{3}$; $3\sqrt{2}$; 4

4) 4; $2\sqrt{3}$; $3\sqrt{2}$

**7.** Велосипедчы 6 минут эчендә а километр юл үтә. Әгәр шул ук тизлек белән барса, 35 минут эчендә ул күпме юл үтәр? Мәсьәлә шарты буенча аңлатма языгыз.

**8.** Велосипедчы 40 минут эчендә 3 километр юл үтә. Әгәр шул ук тизлек белән барса, а километр юлны ничә минутта үтәр? Мәсьәләнең шарты буенча аңлатманы языгыз.

**9.** 25 минут эчендә велосипедчы 8 километр юл үтә. Әгәр шул ук тизлек белән барса, а километр юлны ничә минутта үтәр? Мәсьәләнең шарты буенча аңлатманы языгыз.

**10.** $\frac{x^3-6x^2-4x+24}{(x-6)(x-2)}$ вакланмасын кыскартыгыз.

**11.** $a$=0,1 һәм $b$=0,4 булганда, $\frac{a}{a^2-b^2}:\frac{a}{ab-b^2}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**12.** a=0,2 һәм b=1,5 булганда, $\frac{b}{a^2-ab}:\frac{b}{a^2-b^2}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**13.** $\sqrt{67}+\sqrt{61}$ һәм 16 саннарын чагыштырыгыз.

**14.** 3+$\sqrt{5}$ һәм $\sqrt{8}+\sqrt{6}$ саннарының кайсы зуррак?

**15.** Август ае буенча кыярларның бәясе 20% ка төште, ә аннан соң сентябрь аенда 40% ка күтәрелде. Бәяләр кайчан югарырак булган: август башындамы яки сентябрь аендагысымы? Һәм ничә процентка?

**16.** Бакыр кушылган ике эретмә бар: беренчесендә - 60%, ә икенчесендә – 45% бакыр. Составында 55% бакыр булган яңа эретмә алу өчен, бирелгән эретмәләрне нинди чагыштырмада алырга кирәк?

**17.** Кибет складтан футболкалар сатып ала һәм аны алган бәядән 70% ка артыграк бәя белән сата. Ел ахырында бәяләрне 40% ка төшерәләр. Бәяләр кайчан югарырак булган: кибет футболкаларны сатып алгандамы яки ел ахырындагысымы? Ничә процентка югарырак булган?

**18.** 1 санынан башлап, эзлекле рәвештә натураль саннарны кушалар. Сумма 561 дән кечкенәрәк булырлык итеп, иң күп микъдарда шундый ничә санны кушарга мөмкин?

**19.** $p$ ның кыйммәтләре нинди булганда, $y=-x^2+2px+3$ һәм $y=x^2-px+p$ параболаларының түбәләре $x$ күчәренең төрле ягында яталар?

**20.** 11,2; 10,8; …арифметик прогрессиясенең барлык уңай буыннарының суммасын табыгыз.

**21.** Парабола $A(0;6)$, $B(6;-6)$, $C(1;9)$ нокталары аша үтә. Аның түбәләренең координаталарын табыгыз.

**22.** 1 санынан башлап, эзлекле рәвештә натураль саннарны кушалар. Сумма 378 дән зуррак булырлык итеп, иң аз микъдарда шундый ничә санны кушарга мөмкин?

**23.** Аңлатманы кыскартыгыз: $\frac{ab+5b+10+2a}{a^2-25}$.

**24.** Парабола $K(0;2)$, $L(-5;-3)$, $M(1;9)$ нокталары аша үтә. Аның түбәләренең координаталарын табыгыз.

**25.** $\sqrt{23}+\sqrt{27}$ һәм 10 саннарын чагыштырыгыз.

**26.** Парабола $A(0;-6)$, $B(1;-9)$, $C(6;6)$ нокталары аша үтә. Аның түбәләренең координаталарын табыгыз.

**27.** Аңлатманы кыскартыгыз: $\dfrac{ab+4b-2a-8}{a^2-16}$.

**28.** $m$ның кыйммәтләре нинди булганда, $y=x^2+4mx+2m$ һәм $y=-x^2+2mx+4$ параболаларының түбәләре $x$ күчәренең бер ягында яталар?

**29.** n теләсә нинди булганда, түбәндәге аңлатмаларның кайсы $8\cdot2^n$ тапкырчыгышына тигез?

1) $16^n$

2) $2^{3n}$

3) $2^{n+3}$

4) $8^{n+1}$

**30.** n теләсә нинди булганда, түбәндәге аңлатмаларның кайсы $16\cdot2^n$ тапкырчыгышына тигез?

1) $2^{n+4}$

2) $2^{4n}$

3) $32^n$

4) $32^{n+4}$

**31.** Түбәндә бирелгән саннарның кайсы $\sqrt{75\cdot60}\cdot\sqrt{90}$ аңлатмасының кыйммәте була?

1) 900

2) $450\sqrt{10}$

3) $450\sqrt{6}$

4) $450\sqrt{2}$

**32.** Түбәндә бирелгән саннарның кайсы $\sqrt{18\cdot72}\cdot\sqrt{30}$ аңлатмасының кыйммәте була?

1) $36\sqrt{30}$

2) $72\sqrt{15}$

3) $180\sqrt{6}$

4) $108\sqrt{10}$

**33.** Түбәндә бирелгән аңлатмаларның кайсы рациональ сан була?

1) $\sqrt{18}\cdot\sqrt{7}$

2) $(\sqrt{9}-\sqrt{14})\cdot(\sqrt{9}+\sqrt{14})$

3) $\dfrac{\sqrt{22}}{\sqrt{2}}$

4) $\sqrt{54}+3\sqrt{6}$

**34.** Түбәндә бирелгән аңлатмаларның кайсы рациональ сан була?

1) $\sqrt{18}\cdot\sqrt{4}$

2) $(\sqrt{23}-\sqrt{20})\cdot(\sqrt{23}+\sqrt{20})$

3) $\dfrac{\sqrt{40}}{\sqrt{6}}$

4) $\sqrt{24}-3\sqrt{6}$

**35.** Түбәндә бирелгән саннар арасыннан $\dfrac{9^{-5}\cdot 9^{-4}}{9^{-6}}$ аңлатмасының кыйммәте булганын сайлап алыгыз.

1) -729

2) $\dfrac{1}{729}$

3) $-\dfrac{1}{729}$

4) 729

**36.** Түбәндә бирелгән саннар арасыннан $\dfrac{3^{-9}\cdot 3^{-8}}{3^{-12}}$ аңлатмасының кыйммәте булганын сайлап алыгыз.

1) $-\dfrac{1}{243}$

2) 243

3) $\dfrac{1}{243}$

4) $-243$

**37.** Дүртпочмаклык мәйданы $S=\frac{d_1 d_2 \sin\alpha}{2}$ формуласы белән исәпләнә, $d_1$ һәм $d_2$ — дүртпочмаклыкның диагональләре озынлыклары, α — диагональләр арасындагы почмак. Әгәр $d_1$ =9, sinα $=\frac{5}{8}$, ә $S$=56,25 булса, $d_2$ не табыгыз.

**38.** Дүртпочмаклык мәйданы $S=\frac{d_1 d_2 \sin\alpha}{2}$ формуласы белән исәпләнә, $d_1$ һәм $d_2$ — дүртпочмаклыкның диагональләре озынлыклары, α — диагональләр арасындагы почмак. Әгәр $d_1$ =17, sinα$=\frac{1}{3}$, ә $S$=51 булса, $d_2$ не табыгыз.

**39.** Дүртпочмаклык мәйданы $S=\frac{d_1 d_2 \sin\alpha}{2}$ формуласы белән исәпләнә, $d_1$ һәм $d_2$ — дүртпочмаклыкның диагональләре озынлыклары, α — диагональләр арасындагы почмак. Әгәр $d_1$ =6, sinα$=\frac{1}{11}$, ә $S$=3 булса, $d_2$ не табыгыз.

**40.** Температура кыйммәтен Фаренгейт шкаласыннан Цельсий шкаласына күчерү өчен, $t_C=\frac{5}{9}(t_F-32)$ формуласы кулланыла. $t_C$ — Цельсий градусларындагы температура, $t_F$ — Фаренгейт градусларындагы температура. Фаренгейт шкаласындагы 103 градус Цельсий шкаласында ничә градуска тигез?

**41.** Температура кыйммәтен Фаренгейт шкаласыннан Цельсий шкаласына күчерү өчен, $t_C=\frac{5}{9}(t_F-32)$ формуласы кулланыла. $t_C$ —Цельсий градусларындагы температура, $t_F$ — Фаренгейт градусларындагы температура. Фаренгейт шкаласындагы 50 градус Цельсий шкаласында ничә градуска тигез?

**42.** Даими ток егәрлеге (ваттларда) $P=I^2R$ формуласы буенча исәпләнә. I — ток зурлыгы (Амперларда), R — каршылык (Омларда). Әгәр егәрлек 6,75 Вт, ток зурлыгы 1,5 А булса, R каршылыгын табыгыз. Җавапны Омларда бирегез.

**43.** Даими ток егәрлеге (ваттларда) $P=I^2R$ формуласы буенча исәпләнә. I — ток зурлыгы (Амперларда), R — каршылык (Омнарда). Әгәр егәрлек 15,75 Вт, ток зурлыгы 1,5 А булса, R каршылыгын табыгыз. Җавапны Омнарда бирегез.

**44.** Әйләнә буенча хәрәкәт вакытында үзәккә омтылу тизләнеше (м/с$^2$) $a=\omega^2R$ формуласы буенча исәпләнә. ω — почмакча тизлек (с$^{-1}$), R — әйләнә радиусы (метрларда). Әгәр почмакча тизлек 7,5 с$^{-1}$, үзәккә омтылу тизләнеше 337,5 м/с$^2$ булса, R радиусын табыгыз. Җавапны метрларда бирегез.

**45.** Әйләнә буенча хәрәкәт вакытында үзәккә омтылу тизләнеше (м/с$^2$) $a=\omega^2R$ формуласы буенча исәпләнә. ω — почмакча тизлек (с$^{-1}$), R — әйләнә радиусы (метрларда). Әгәр почмакча тизлек 6 с$^{-1}$, үзәккә омтылу тизләнеше 72 м/с$^2$ булса, R радиусын табыгыз. Җавапны метрларда бирегез.

**46.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $(7\cdot 10^3)^2\cdot(16\cdot 10^{-4})$.

**47.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $(9\cdot10^{-2})^2\cdot(11\cdot10^5)$.

**48.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $(8\cdot10^2)^2\cdot(3\cdot10^{-2})$.

**49.** $y=5-\frac{x+5}{x^2+5x}$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән уртак нокталары булмый?

**50.** $y=1-\frac{x+5}{x^2+5x}$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән уртак нокталары булмый?

**51.** $y=\frac{9x+1}{9x^2+x}$ функциясенең графигын төзегез. k ның кыйммәтләре нинди булганда, y=kx турысының график белән бер уртак ноктасы була?

**52.** $y=\frac{6x+7}{6x^2+7x}$ функциясенең графигын төзегез. k ның кыйммәтләре нинди булганда, y=kx турысының график белән бер уртак ноктасы була?

**53.** $y=|x|(x+1)-5x$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән ике уртак ноктасы бар?

**54.** $y=|x|(x+2)-3x$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән ике уртак ноктасы бар?

**55.** $y=\frac{1}{2}\left(\left|\frac{x}{6}-\frac{6}{x}\right|+\frac{x}{6}+\frac{6}{x}\right)$ функциясенең графигын төзегез. k ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән бер уртак ноктасы була?

**56.** $y=\frac{1}{2}\left(\left|\frac{x}{4,5}-\frac{4,5}{x}\right|+\frac{x}{4,5}+\frac{4,5}{x}\right)$ функциясенең графигын төзегез. k ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән бер уртак ноктасы була?

**57.** $y=\frac{(x^2+x-12)(x^2-3x+2)}{x^2-4x+3}$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән бер уртак ноктасы бар?

**58.** $y=\frac{(x^2-2x-3)(x^2-3x+2)}{x^2-4x+3}$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән бер уртак ноктасы бар?

**59.** Тигезләмәне чишегез: $(x-2)^2(x-4)=24(x-2)$.

**60.** Тигезләмәне чишегез: $(x-2)^2(x-5)=18(x-2)$.

**61.** Тигезләмәне чишегез: $(x-2)^2(x-5)=28(x-2)$.

**62.** Әгәр $f(x-4)=6^{8-x}$ булса, f(2) не табыгыз.

**63.** Әгәр $f(x+4)=4^{4-x}$ булса, f(5) не табыгыз.

**64.** Әгәр $f(x+1)=4^{5-x}$ булса, f(4) не табыгыз.

**65.** Математик маятникның тирбәнү периоды (секундларда) якынча $T=2\sqrt{l}$ формуласы белән исәпләнә. $l$ — җеп озынлыгы (метрларда). Тирбәнү периоды 10 секунд булганда, җепнең озынлыгын (метрларда) табыгыз.

**66.** Математик маятникның тирбәнү периоды (секундларда) якынча $T=2\sqrt{l}$ формуласы белән исәпләнә. $l$ — җеп озынлыгы (метрларда). Тирбәнү периоды 19 секунд булганда, җепнең озынлыгын (метрларда) табыгыз.

**67.** Менделеев–Клапейрон законын $PV=\nu RT$ рәвешендә язарга мөмкин, монда P - басым (паскальләрдә), V - күләм ($м^3$), $\nu$ - матдә микъдаре (мольләрдә), T - температура (Кельвиннарда). R= 8,31 Дж/(К · моль) - универсаль газ константасы. Әгәр $\nu$=87,2 моль, P=90 579 Па, V=7,2 $м^3$ булса, формуланы кулланып, температураны исәплəгез (T, Кельвиннарда).

**68.** Менделеев–Клапейрон законын $PV=\nu RT$ рәвешендә язарга мөмкин, монда P - басым (паскальләрдә), V - күләм ($м^3$), $\nu$ - матдә микъдаре (мольләрдә), T - температура (Кельвиннарда). R= 8,31 Дж/(К · моль)- универсаль газ константасы. Әгәр T=450 К, P=59 665,8 Па, $\nu$=71,8 моль булса, формуланы кулланып, күләмне исәплəгез (V, $м^3$).

**69.** $\dfrac{x^{-8}\cdot x^{10}}{x^{4}}$ вакланмасын түбәндәге кайсы аңлатмага үзгәртеп була?

1) $x^8$

2) $a^{-3}$

3) $x^6$

4) $x^{-2}$

**70.** $\dfrac{a^{-8}}{a^{4}\cdot a^{-9}}$ вакланмасын түбәндәге кайсы аңлатмага үзгәртеп була?

1) $a^{-3}$

2) $a^7$

3) $a^{-13}$

4) $a^4$

**71.** $y=|x^2-4x+3|$ функциясенең графигын төзегез. График белән абсциссалар күчәренә параллель турының мөмкин булган ничә уртак ноктасы бар?

**72.** $y=|x^2-9|$ функциясенең графигын төзегез. График белән абсциссалар күчәренә параллель турының мөмкин булган ничә уртак ноктасы бар?

**73.** $y=|x^2+3x+2|$ функциясенең графигын төзегез. График белән абсциссалар күчәренә параллель турының мөмкин булган ничә уртак ноктасы бар?

**74.** $y=\frac{x+5}{x^2+5x}$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән уртак нокталары юк?

**75.** $y=\frac{x+2}{x^2+2x}$ функциясенең графигын төзегез. m ның кыйммәтләре нинди булганда, y=m турысының график белән уртак нокталары юк?

**76.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $(4{,}8\cdot10^{-2})(8\cdot10^{-2})$.

**77.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $(6{,}8\cdot10^{-3})(2\cdot10^{-3})$.

**78.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $(6{,}9\cdot10^{-2})(9\cdot10^{-3})$.

**79.** Әгәр $a=4\frac{7}{13}$, $b=8\frac{6}{13}$ булса, $\frac{a^2-b^2}{ab}:\left(\frac{1}{b}-\frac{1}{a}\right)$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**80.** Әгәр $a=3\frac{11}{19}$, $b=7\frac{8}{19}$ булса, $\frac{a^2-b^2}{ab}:\left(\frac{1}{b}-\frac{1}{a}\right)$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**81.** Әгәр $a=1\frac{3}{7}$, $b=2\frac{4}{7}$ булса, $\frac{a^2-b^2}{ab}:\left(\frac{1}{b}-\frac{1}{a}\right)$ аңлатмасының кыйммәтен абыгыз.

**82.** Әгәр $a=\sqrt{3}$, $b=\sqrt{2}$ булса, $-12ab+(2a+3b)^2$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**83.** Әгәр $a=0{,}5$, $b=\sqrt{7}-2$ булса, $\left(\frac{a+b}{a^2-ab}-\frac{1}{a}\right):\frac{b}{b-a}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**84.** Әгәр $a=-0{,}25$, $b=\sqrt{5}-1$ булса, $\left(\frac{m-n}{m^2+mn}+\frac{1}{m}\right):\frac{m}{m+n}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**85.** Әгәр $b=9{,}4$ булса, $(8b-3)(3b+8)-3b(8b+3)$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**86.** $x^2+px+q=0$ тигезләмәсенең тамырлары: $-3$ һәм 3. q ны табыгыз.

**87.** $x^2+px+q=0$ тигезләмәсенең тамырлары: $-9$ һәм 1. q ны табыгыз.

**88.** $x^2+px+q=0$ тигезләмәсенең тамырлары: $-4$ һәм $-1$. q ны табыгыз.

**89.** Квадрат өчбуын тапкырлаучыларга таркатылган: $5x^2+43x+24=5(x+8)(x-a)$. a санын табыгыз.

**90.** Квадрат өчбуын тапкырлаучыларга таркатылган: $2x^2-11x+5=2(x-5)(x-a)$. a санын табыгыз.

**91.** Квадрат өчбуын тапкырлаучыларга таркатылган: $2x^2 - 13x+15=2(x-5)(x-a)$. а санын табыгыз.

**92.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\sqrt{6\cdot 27}\cdot\sqrt{90}$.

1) $54\sqrt{15}$

2) $54\sqrt{10}$

3) $54\sqrt{5}$

4) 270

**93.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\sqrt{30\cdot 8}\cdot\sqrt{60}$.

1) $120\sqrt{2}$

2) $120\sqrt{3}$

3) 120

4) $120\sqrt{5}$

**94.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\sqrt{3\cdot 50}\cdot\sqrt{60}$.

1) $60\sqrt{5}$

2) $150\sqrt{2}$

3) $30\sqrt{30}$

4) $30\sqrt{10}$

**95.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\sqrt{3\cdot 7^2}\cdot\sqrt{3\cdot 2^4}$.

1) 84

2) 2352

3) $28\sqrt{3}$

4) 252

**96.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\sqrt{5\cdot 2^4}\cdot\sqrt{5\cdot 3^2}$.

1) 60

2) $12\sqrt{5}$

3) 300

4) 720

**97.** Бирелгән аңлатмаларның кайсылары иң кечкенә кыйммәтләргә ия була?

1) $\sqrt{10}$

2) $2\sqrt{3}$

3) $(\sqrt{3})^2$

4) $\frac{\sqrt{18}}{\sqrt{3}}$

**98.** Бирелгән аңлатмаларның кайсылары иң зур кыйммәтләргә ия була?

1) $\sqrt{30}$

2) $2\sqrt{10}$

3) $(\sqrt{6})^2$

4) $\frac{\sqrt{42}}{\sqrt{3}}$

**99.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\frac{\sqrt{32}}{\sqrt{8}}$

1) 2

2) $4\sqrt{8}$

3) $2\sqrt{8}$

4) 16

**100.** $\frac{1}{x^{-6}} \cdot \frac{1}{x^{9}}$ аңлатмасын түбәндәге аңлатмаларның кайсына үзгәртергә була?

1) $x^{54}$

2) $x^{3}$

3) $x^{-54}$

4) $x^{-3}$

**101.** $\frac{1}{x^{2}} \cdot \frac{1}{x}$ аңлатмасын түбәндәге аңлатмаларның кайсына үзгәртергә була?

1) $x^{-3}$

2) $x^{3}$

3) $x^{2}$

4) $x^{-2}$

**102.** $\frac{1}{x^{-7}} \cdot \frac{1}{x^{3}}$ аңлатмасын түбәндәге аңлатмаларның кайсына үзгәртергә була?

1) $x^{-4}$

2) $x^{4}$

3) $x^{-21}$

4) $x^{21}$

**103.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\frac{5^{-7} \cdot 5^{-3}}{5^{-7}}$.

1) $\frac{1}{125}$

2) $-125$

3) $-\frac{1}{125}$

4) 125

**104.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\frac{5^{-6} \cdot 5^{-6}}{5^{-10}}$.

1) $\frac{1}{25}$

2) 25

3) $-\frac{1}{25}$

4) -25

**105.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $\frac{2^{-7} \cdot 2^{-3}}{2^{-7}}$.

1) -8

2) 8

3) $-\frac{1}{8}$

4) $\frac{1}{8}$

**106.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $8\sqrt{2} \cdot \sqrt{3} \cdot 2\sqrt{6}$.

1) 24

2) 48

3) 96

4) 576

**107.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $8\sqrt{3}\cdot\sqrt{2}\cdot 2\sqrt{6}$ .

1) 24

2) 48

3) 96

4) 576

**108.** Аңлатманың кыйммәтен табыгыз: $2\sqrt{3}\cdot\sqrt{6}\cdot 8\sqrt{2}$ .

1) 384

2) 576

3) 24

4) 96

**109.** Бөтендөнья тартылу законы $F=\gamma\dfrac{m_1m_2}{r^2}$ формуласы белән бирелә. Монда $F$ — җисемнәр арасындагы тартылу көче (ньютоннарда), $m_1$ һәм $m_2$ — җисемнәрнең массасы (килограммнарда), $r$ — ике җисемнең үзәкләре арасындагы ераклык (метрларда), $\gamma$ = 6,67·$10^{-11}$ Н · $м^2$ /$кг^2$ — гравитация константасы. Әгәр $F$=41,6875 Н, $m_2$=5·$10^9$ кг, $r$=4 м булса, формуланы кулланып, $m_1$ массасын табыгыз.

**110.** Бөтендөнья тартылу законы $F=\gamma\dfrac{m_1m_2}{r^2}$ формуласы белән бирелә. Монда $F$— җисемнәр арасындагы тартылу көче (ньютоннарда), $m_1$ һәм $m_2$ — җисемнәрнең массасы (килограммнарда), $r$ — ике җисемнең үзәкләре арасындагы ераклык (метрларда), γ=6,67·$10^{-11}$ Н · $м^2$ /$кг^2$ — гравитация константасы. Әгәр $F$=4,002 Н, $m_2$=4·$10^9$ кг, $r$=2 м булса, формуланы кулланып, беренче җисемнең $m_1$ массасын табыгыз.

**111.** Тигезләмәне чишегез: $(x^2-49)^2+(x^2+4x-21)^2=0$.

**112.** Тигезләмәне чишегез: $(x^2-4)^2+(x^2-3x-10)^2=0$.

**113.** Тигезләмәне чишегез: $(x^2-9)^2+(x^2+x-6)^2=0$.

**114.** Тигезләмәне чишегез: $x^2-3x+\sqrt{6-x}=\cdot\sqrt{6-x}+28$.

**115.** Тигезләмәне чишегез: $x^2-2x+\sqrt{5-x}=\cdot\sqrt{5-x}+24$.

**116.** Тигезләмәне чишегез: $x^2-2x+\sqrt{6-x}=\cdot\sqrt{6-x}+35$.

**117.** Тигезләмәне чишегез: $x^3+7x^2=\cdot 4x+28$.

**118.** Тигезләмәне чишегез: $x^3+4x^2=\cdot 9x+36$.

**119.** Тигезләмәне чишегез: $x^3+5x^2=\cdot 4x+20$.

**120.** Әгәр $\dfrac{2a-5b+7}{5a-2b+7}=6$ булса, $28a-7b+40$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**121.** Әгәр $\frac{3a-4b+8}{4a-3b+8}=9$ булса, $33a-23b+71$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**122.** Әгәр $\frac{a-6b+5}{6a-b+5}=7$ булса, $41a-b+45$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**123.** $a=34$, $c=83$ булганда, $\frac{a}{4c}-\frac{a^2+16c^2}{4ac}+\frac{4c-a}{a}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**124.** $a=10$, $c=16$ булганда, $\frac{5a}{4c}-\frac{25a^2+16c^2}{20ac}+\frac{4c-25a}{5a}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**125.** $a=34$, $c=86$ булганда, $\frac{5a}{9c}-\frac{25a^2+81c^2}{45ac}+\frac{9c-25a}{5a}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**126.** Тигезләмәне чишегез: $(x-3)(x-4)(x-5)=(x-2)(x-4)(x-5)$.

**127.** $p(b)=\left(b+\frac{5}{b}\right)\left(5b+\frac{1}{b}\right)$ булса, $\frac{p(b)}{p\left(\frac{1}{p}\right)}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.

**128.** $p(b)=\left(b+\frac{10}{b}\right)\left(10b+\frac{1}{b}\right)$ булса, $\frac{p(b)}{p\left(\frac{1}{p}\right)}$ аңлатмасының кыйммәтен табыгыз.